| | |
|---|---|
| Республика Татарстан | Татарстан Республикасы |
| Менделеевский городской Совет<br>Менделеевского<br>муниципального района | Менделеевск муниципаль районы<br>Менделеевск<br>шәһәр Советы |

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.04.2025 Менделеевск ш. № 93

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Менделеевск шәһәре башлыгы һәм
Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Менделеевск
шәһәр Советы депутатының 4 нче
Менделеевск бермандатлы сайлау
округы буенча вәкаләтләрен вакытыннан
алда туктату турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 6 өлешенең 2 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Менделеевск шәһәре” Уставының 47 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты, 37 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты, Беляев Радмир Илдар улының шәхси гаризасы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советы

КАРАР КЫЛДЫ;

1. Беляев Радмир Илдар улының Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре башлыгы һәм 4 нче Менделеевск бермандатлы сайлау округы буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Менделеевск шәһәр Советы депутаты вазыйфасыннан шәхси гаризасы нигезендә үз теләге белән отставкага китүен кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәре башлыгы һәм 4 нче Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советы депутаты Беляев Радмир Илдар улының вәкаләтләрен 2025 елның 23 апрелендә вакытыннан алда туктатылган дип санарга.
3. Әлеге карарны «Менделеевск яңалыклары» газетасында бастырып чыгарырга, Менделеевск муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

Шәһәр Советы рәисе урынбасары Н.Н.Сөләйманов